Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Ямбакты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№1

21 октябрь 2019 ел.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Ямбакты авыл жирлеге составына керүче
Ямбакты авылындагы халык җыены нәтиҗәләре
турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлегендә гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге составына керүче Ямбакты авылындагы халык җыенын халык җыены нәтиҗәләрен –чын мәгънәсендә дип танырга.

2. Кабул ителгән карарны түбәндәге мәсьәлә буенча танырга:

- Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге Ямбакты авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 250 сум күләмендә үзара салым кертергә килешәсезме?

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эш төрләрен башкаруга юнәлдерергә:

-Ямбакты авылында коры агач-чүп үләннәре, куаклар кисү (килешү буенча эш өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу););

- Ямбакты авылындагы энергия саклаучы лампаларны, яктырткычларны, махсус җиһазларны сатып алу, урнаштыру ( килешү буенча эш өчен түләү););

- Һәйкәлләрне урнаштыру һәм реконструкцияләү.

- Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган сугышчылар исемнәре язылган мемориаль такта сатып алу һәм урнаштыру.(Килешү буенча түләү)

4. Халык җыены карарын Ямбакты авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән һәм Интернет челтәренең рәсми сайтында (http:// spasskiy.tatarstan.ru һәм ТР хокукый мәгълүмат рәсми порталында (//http:pravo.tatarstan.ru) игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Ямбакты авыл җирлеге башлыгы И.Ә. Галәветдинов